**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 31 декабрь № 1045

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елда агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2015 ел, 26 февраль, 120 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елда агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2015 ел, 26 февраль, 120 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 10 апрель, 233 нче; 2015 ел, 11 июнь, 441 нче; 2015 ел, 15 июль, 513 нче; 2015 ел, 14 август, 590 нчы; 2015 ел, 27 ноябрь, 901 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«2015 елда крестьян (фермер) хуҗалыкларына ана кәҗәләрне һәм бер яшьтән зуррак кәҗәләрне карап тоту чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе;

2015 елда авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына матди-техник базаны үстерүгә грантлар бирү тәртибе;

2015 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплекслары (сөт фермалары) төзү эшләрен башкаруга бәйле булган чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибе;

2015 елда «2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында итле терлекчелекне үстерү» икътисадый әһәмияттәге ведомство максатчан төбәк программасын тормышка ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү тәртибе;

2015 елда «2015 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү» икътисадый әһәмияттәге ведомство максатчан төбәк программасын тормышка ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү тәртибе;

2015 елда сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) төзү һәм (яки) модернизацияләү өчен турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе.»;

2 нче пунктта:

икенче абзацта «20,0 млн.сум» сүзләрен «20 000,0 мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «20,0 млн.сум» сүзләрен «20 000,0 мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «50,0 млн.сум» сүзләрен «27 843,0 мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «100,0 млн.сум» сүзләрен «30 453,0 мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына – 4 707,0 мең сум күләмендә.»;

әлеге карар белән расланган 2015 елга агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү өчен «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законында каралган финанслау күләмнәрен бүлүдә:

1 нче пунктта «1 494 151,0» саннарын «1 458 595,6» саннарына алмаштырырга;

7 нче пунктта «154 230,0» саннарын «230 260,0» саннарына алмаштырырга;

10 нчы пунктта «4 200,0» саннарын «9 200,0» саннарына алмаштырырга;

11 нче пунктта «30 000,0» саннарын «36 000,0» саннарына алмаштырырга;

14 нче пунктта:

«319 993,6» саннарын – «369 592,0» саннарына, «88 601,6» саннарын «104 200,0» саннарына алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| | «сөтле терлекчелек объектларын төзү һәм төзекләндерүгә | 34 000,0»; |

16 нчы пунктта:

«160 006,4» саннарын – «191 000,0» саннарына, «110 006,4» саннарын «120 000,0» саннарына алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| | «үсемлекчелек һәм терлекчелек продукциясен эшкәртүгә | 20 000,0 |
| | сөтле терлекчелекне үстерү | 1 000,0»; |

17 нче пунктта «1 835 680,0» саннарын «1 855 680,0» саннарына алмаштырырга;

20 нче пунктта «40 400,0» саннарын «38 400,0» саннарына алмаштырырга;

21 нче пунктта «9 600,0» саннарын «7 600,0» саннарына алмаштырырга;

24 нче пунктта «63 000,0» саннарын «73 000,0» саннарына алмаштырырга;

26 нчы пунктта «50 000,0» саннарын «27 843,0» саннарына алмаштырырга;

27 нче пунктта «70 000,0» саннарын «30 453,0» саннарына алмаштырырга;
28 нче пунктта «85 000,0» саннарын «58 510,0» саннарына алмаштырырга;
29 нчы пунктта «691 500,0» саннарын «485 416,2» саннарына алмаштырырга;
30 нчы пунктта «13 597,3» саннарын «29 397,3» саннарына алмаштырырга;
31 нче пунктта «67 500,0» саннарын «57 000,0» саннарына алмаштырырга;
32 нче пунктта «37 327,0» саннарын «9 855,0» саннарына алмаштырырга;
37 нче пунктта «360 000,0» саннарын «349 254,0» саннарына алмаштырырга;
таблицага түбәндәге эчтәлекле 38 – 42 нче пунктлар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «38 | Крестьян (фермер) хуҗалыкларына ана кәҗәләрне һәм бер яшьтән зуррак кәҗәләрне карап тоту чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр | 1 091,0 |
| 39 | Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына матди-техник базаны үстерүгә грантлар бирү | 4 707,0 |
| 40 | Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплекслары (сөт фермалары) төзү эшләрен башкаруга бәйле булган чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидияләр | 80 000,0 |
| 41 | «2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында итле терлекчелекне үстерү» икътисадый әһәмияттәге ведомство максатчан төбәк программасын тормышка ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр | 110 000,0 |
| 42 | «2015 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү» икътисадый әһәмияттәге ведомство максатчан төбәк программасын тормышка ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр | 20 000,0 |
| 43 | Сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) төзү һәм (яки) модернизацияләү өчен турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр | 189,0»; |

«Барлыгы» юлында «7 066 922,6» саннарын «7 113 780,4» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2015 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә үсемлекчелек өлкәсендә файдалану юнәлешләре мөстәкыйль билгеләнә торган ярдәм күрсәтүгә субсидияләр бирү тәртибендә:

беренче абзацта «966350,8» саннарын «943210,9» саннарына алмаштырырга;

икенче абзацта «366350,8» саннарын «350467,4» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «600000,0» саннарын «592743,5» саннарына алмаштырырга;

8 нче пунктта:

беренче абзацта «966350,8» саннарын «943210,9» саннарына алмаштырырга;

«а» пунктчасының беренче абзацында «366350,8» саннарын «350467,4» саннарына алмаштырырга;

«б» пунктчасының беренче абзацында «600000,0» саннарын «592743,5» саннарына алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

бу карар белән расланган 2015 елга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең сатып алынган оригиналь һәм затлы орлыклар буенча чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибендә:

7 нче пунктта «26602,8» саннарын «30934,8» саннарына алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

бу карар белән расланган 2015 елда Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә чиста канлы менге токымнардан булган нәсел атлары үрчетүгә бәйле булган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибендә:

5 нче пунктта «41,585» саннарын «91,090» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2015 елда Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә чиста канлы менге токымнардан булган нәсел атлары үрчетүгә бәйле булган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибенә 1 нче һәм 2 нче кушымталарны (карарга теркәләләр) яңа редакциядә бәян итәргә;

бу карар белән расланган 2015 елда авыл хуҗалыгы җитештерүен техник һәм технологик модернизацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибенә теркәлгән кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган 2015 елда ветеринария-санитария савыктыруы чараларын финанслау тәртибендә:

3 нче пунктта «лаборатория җиһазлары» сүзләреннән соң «, ветеринария мәгълүмат лаборатория системасының программа-аппарат комплекслары» сүзләрен өстәргә;

әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымтада:

45 нче пунктта «18 800» саннарын «28 800» саннарына алмаштырырга;

«Барлыгы» юлында «63 000,0» саннарын «73 000,0» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2015 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге агросәнәгать комплексы оешмаларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына оешмалар милкенә салым түләүгә чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибендә:

5 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әгәр хисап кварталында предприятие тарафыннан тулаем продуктның (акчалата керемнең) күрсәткече буенча шарт үтәлмәсә, предприятие киләсе хисап чорларында алдагы кварталлардан артта калуны компенсацияләде һәм узган елның шушы чоры дәрәҗәсеннән ким булмаган, арта барган нәтиҗә белән тулаем продуктның (акчалата керемнең) күрсәткеченә ирешә дигән шарт белән, предприятие бу квартал өчен субсидияләрне хисап елы чикләрендә киләсе хисап чорларында алырга мөмкин.»;

әлеге карар белән расланган 2015 елда авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә катнашкан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә, кулланучылар җәмгыятьләренә, агросәнәгать комплексы оешмаларына, индивидуаль эшмәкәрләргә

һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга ягулык-майлау материалларына чыгымнарын каплау өчен субсидияләр бирү тәртибендә:

5 нче пунктта «2015 елның 8 маена кадәр» сүзләрен «2015 елның 28 ноябренә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2015 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга мөгезле эре терлектән булган таналарны сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибенә теркәлгән кушмтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

бу карар белән расланган 2015 елда крестьян (фермер) хуҗалыкларына, шәхси эшмәкәрләрне дә кертеп, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр арасыннан алар файдаланган җир кишәрлекләрен милеккә рәсмиләштерү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибендә:

6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Субсидияләр хуҗалыкларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән, гамәлдәге чыгымнарның 25 проценты күләмендә, ләкин алар тарафыннан милеккә рәсмиләштерелгән җир кишәрлекләренең бер гектарына күп дигәндә 168,0 сум күләмендә бирелә.»;

әлеге карар белән расланган 2015 елда шәхси ярдәмче хуҗалыгы булган гражданнарга савым сыерларын, ана кәҗәләрне һәм бер яшьтән зуррак кәҗәләрне карап тоту буенча чыгымнарның бер өлешен кире кайтаруга субсидияләр бирү тәртибенә 1 нче һәм 2 нче кушымталарны (карарга теркәләләр) яңа редакциядә бәян итәргә;

әлеге карарга 2015 елда крестьян (фермер) хуҗалыкларына ана кәҗәләрне һәм бер яшьтән зуррак кәҗәләрне карап тоту чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен, 2015 елда авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына матди-техник базаны үстерүгә грантлар бирү тәртибен, 2015 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплекслары (сөт фермалары) төзү эшләрен башкаруга бәйле булган чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибен, 2015 елда «2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында итле терлекчелекне үстерү» икътисадый әһәмияттәге ведомство максатчан төбәк программасын тормышка ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү тәртибен, 2015 елда «2015 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү» икътисадый әһәмияттәге ведомство максатчан төбәк программасын тормышка ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү тәртибен, 2015 елда сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) төзү һәм (яки) модернизацияләү өчен турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен (карарга теркәләләр) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\1045.doc

2015 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә үсемлекчелек өлкәсендә файдалану юнәлешләре мөстәкыйль билгеләнә торган ярдәм күрсәтүгә субсидияләр бирү тәртибенә кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының
2015 ел, 31 декабрь, 1045 нче карары редакциясендә)

2015 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә үсемлекчелек өлкәсендә файдалану юнәлешләре мөстәкыйль билгеләнә торган ярдәм күрсәтүгә субсидияләр бирүгә финанслау лимитларын
Татарстан Республикасы муниципаль районнары буенча бүлү

| Т/с | Муниципаль район, дәүләт ярдәме юнәлеше исеме | Финанслау лимиты, барлыгы, мең сум | Шул исәптән 1 гектар чәчүлек мәйданына түбәндәгеләр исәбеннән чыгып | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 183,48 сум туфраклар бонитетына төзәтү коэффициентын исәпкә алып | 205,99 сум |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | Әгерҗе | 22 095,0 | 9 958,6 | 12 136,4 |
| 2 | Азнакай | 33 716,3 | 12 772,8 | 20 943,5 |
| 3 | Аксубай | 18 023,3 | 3 129,4 | 14 893,9 |
| 4 | Актаныш | 32 530,3 | 13 893,2 | 18 637,1 |
| 5 | Алексеевск | 27 953,0 | 9 078,0 | 18 875,0 |
| 6 | Әлки | 32 641,6 | 14 669,4 | 17 972,2 |
| 7 | Әлмәт | 22 700,0 | 7 395,5 | 15 304,5 |
| 8 | Апас | 23 413,3 | 9 617,5 | 13 795,8 |
| 9 | Арча | 35 492,3 | 10 893,1 | 24 599,2 |
| 10 | Әтнә | 17 936,2 | 8 693,8 | 9 242,4 |
| 11 | Баулы | 18 263,4 | 8 156,9 | 10 106,5 |
| 12 | Балтач | 26 098,4 | 12 630,2 | 13 468,2 |
| 13 | Бөгелмә | 18 808,5 | 6 596,1 | 12 212,4 |
| 14 | Буа | 33 225,3 | 13 302,8 | 19 922,5 |
| 15 | Югары Ослан | 13 727,1 | 6 905,7 | 6 821,4 |
| 16 | Биектау | 24 080,5 | 11 041,3 | 13 039,2 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 17 | Чүпрәле | 21 767,5 | 8 123,2 | 13 644,3 |
| 18 | Алабуга | 19 127,2 | 8 034,9 | 11 092,3 |
| 19 | Зәй | 24 119,8 | 10 129,3 | 13 990,5 |
| 20 | Зеленодольск | 13 592,7 | 5 691,4 | 7 901,3 |
| 21 | Кайбыч | 20 019,6 | 8 792,7 | 11 226,9 |
| 22 | Кама Тамагы | 20 337,2 | 9 645,5 | 10 691,7 |
| 23 | Кукмара | 21 638,6 | 6 838,9 | 14 799,7 |
| 24 | Лаеш | 15 125,2 | 5 104,6 | 10 020,6 |
| 25 | Лениногорск | 16 812,7 | 4 633,4 | 12 179,3 |
| 26 | Мамадыш | 25 933,8 | 9 063,2 | 16 870,6 |
| 27 | Менделеевск | 9 745,7 | 4 196,1 | 5 549,6 |
| 28 | Минзәлә | 20 995,1 | 4 446,3 | 16 548,8 |
| 29 | Мөслим | 17 702,1 | 2 972,0 | 14 730,1 |
| 30 | Түбән Кама | 14 924,2 | 5 076,2 | 9 848,0 |
| 31 | Яңа Чишмә | 24 896,4 | 8 094,0 | 16 802,4 |
| 32 | Нурлат | 20 782,1 | 4 205,3 | 16 576,8 |
| 33 | Питрәч | 20 814,4 | 8 630,2 | 12 184,2 |
| 34 | Балык Бистәсе | 29 555,3 | 13 304,6 | 16 250,7 |
| 35 | Саба | 20 243,2 | 10 050,6 | 10 192,6 |
| 36 | Сарман | 28 974,3 | 11 461,9 | 17 512,4 |
| 37 | Спас | 21 995,7 | 8 376,3 | 13 619,4 |
| 38 | Тәтеш | 24 143,9 | 9 728,7 | 14 415,2 |
| 39 | Тукай | 25 799,7 | 10 753,4 | 15 046,3 |
| 40 | Теләче | 12 816,0 | 3 679,7 | 9 136,3 |
| 41 | Чирмешән | 12 547,2 | 0,0 | 12 547,2 |
| 42 | Чистай | 26 691,6 | 6 904,4 | 19 787,2 |
| 43 | Ютазы | 11 405,2 | 3 796,3 | 7 608,9 |
| Муниципаль районнар буенча барлыгы | | 943 210,9 | 350 467,4 | 592 743,5 |
| Кәбестә, бәрәңге һәм яшелчә культуралары биләгән чәчүлек мәйданнарын киңәйтүне саклау һәм стимуллаштыру | | 146 441,6 | | |
| Ябык грунтта яшелчә җитештерүне стимуллаштыру | | 22 000,2 | | |
| Куак булмаган җиләк-җимеш үсентеләренең югары техно-логияле чәчүлек мәйданнарын киңәйтү һәм җитештерүне стимуллаштыру | | 6 000,0 | | |
| Авыл хуҗалыгы культуралары чәчүлекләренә фитосанитария мониторингын үткәрү | | 30 942,9 | | |
| Сапропель минераль-органик | | 10 000,0 | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| ашламалар кертү чыгымнарының бер өлешен каплау | | | |
| 2015 елгы уңыш ашлыгын Төбәк азык-төлек фондына һәм социаль икмәк җитештерү өчен фонд онын сатучы он тарту предприятиеләренә кайтартуны стимуллаштыру | 300 000,0 | | |
| Барлыгы | 1 458 595,6 | | |

F:\KARAR\2015\1045_1.doc

2015 елга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең сатып алынган оригиналь һәм затлы орлыклар буенча чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибенә кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 31 декабрь, 1045 нче карары редакциясендә)

2015 елга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең сатып алынган оригиналь һәм затлы орлыклар буенча чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирүгә финанслау лимитларын
Татарстан Республикасы муниципаль районнары буенча бүлү

| Т/с | Муниципаль районнар, дәүләт ярдәме юнәлешләре исеме | Субсидияләр лимиты, мең сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Әгерҗе | 24,1 |
| 2 | Азнакай | 540,0 |
| 3 | Актаныш | 454,0 |
| 4 | Алексеевск | 174,7 |
| 5 | Әлки | 41,8 |
| 6 | Әлмәт | 403,9 |
| 7 | Апас | 171,0 |
| 8 | Арча | 3 760,2 |
| 9 | Әтнә | 600,9 |
| 10 | Баулы | 185,7 |
| 11 | Балтач | 692,4 |
| 12 | Бөгелмә | 155,6 |
| 13 | Буа | 2 520,6 |
| 14 | Югары Ослан | 323,0 |
| 15 | Биектау | 3 871,9 |
| 16 | Чүпрәле | 581,4 |
| 17 | Алабуга | 580,0 |
| 18 | Зәй | 742,3 |
| 19 | Зеленодольск | 41,3 |
| 20 | Кайбыч | 560,0 |
| 21 | Кама Тамагы | 53,5 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 22 | Кукмара | 1 533,0 |
| 23 | Лаеш | 1 277,6 |
| 24 | Лениногорск | 629,0 |
| 25 | Мамадыш | 539,5 |
| 26 | Менделеевск | 188,4 |
| 27 | Минзәлә | 242,6 |
| 28 | Мөслим | 666,3 |
| 29 | Түбән Кама | 576,4 |
| 30 | Яңа Чишмә | 194,4 |
| 31 | Нурлат | 313,1 |
| 32 | Питрәч | 963,5 |
| 33 | Балык бистәсе | 803,3 |
| 34 | Саба | 3 255,3 |
| 35 | Сарман | 787,9 |
| 36 | Спас | 352,3 |
| 37 | Тәтеш | 502,7 |
| 38 | Тукай | 558,2 |
| 39 | Теләче | 202,3 |
| 40 | Чистай | 475,0 |
| 41 | Ютазы | 395,7 |
| Муниципаль районнар буенча барлыгы | | 30 934,8 |
| Сатып алынган оригиналь һәм затлы рапс орлыклары буенча чыгымнарының бер өлешен каплауга | | 1 077,7 |
| Сатып алынган оригиналь һәм затлы күпьеллык үләннәр орлыклары буенча чыгымнарының бер өлешен каплауга | | 2 116,7 |
| Сортларга экологик зона сынавы | | 1 998,5 |
| Орлыкчылык хуҗалыкларын стимуллаштыру | | 7 492,6 |
| Туфраклы сортлы тикшерү үткәрү | | 1 982,5 |
| Барлыгы | | 45602,8 |

---

F:\KARAR\2015\1045_2.doc

2015 елда нәселле терлекчелеккә булышлык күрсәтү өчен акча бирү тәртибенә 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 31 декабрь, 1045 нче карары редакциясендә)

2015 елда нәселле терлекчелеккә булышлык күрсәтү өчен акча бүлү

| Т/с | Статьялар исеме | Финанслау күләме, мең сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Авыл хуҗалыгы хайваннарының нәселле ана баш санын асрауга субсидияләр | 62 772,1 |
| 2 | Мөгезле эре терлекнең нәселле ана баш санын арттыру буенча чыгымнарны каплауга субсидияләр | 3 853,5 |
| 3 | Нәсел үрчеткеч нәселле үгезләр һәм нәсел үрчеткеч ата дуңгызлар асрауга субсидияләр | 10 665,0 |
| 4 | Нәсел үрчеткеч нәселле үгезләр һәм нәсел үрчеткеч ата дуңгызлар сатып алу чыгымнарын каплау өчен субсидияләр | 6 826,5 |
| 5 | Нәселле авыл хуҗалыгы хайваннары сатып алу чыгымнарын каплауга субсидияләр | 87 254,5 |
| 6 | Нәселле яшь мөгезле эре терлек җитештерү һәм реализацияләү чыгымнарын каплау өчен субсидияләр | 28 363,0 |
| 7 | Итле токымнан булган нәселле мөгезле эре терлек сатып алу чыгымнарын каплау өчен субсидияләр | 1,0 |
| 8 | Нәсел үрчеткеч үгезләр орлыгын җитештерү һәм реализацияләү чыгымнарын каплау өчен субсидияләр | 49 058,9 |
| 9 | Нәсел үрчеткеч ата дуңгызлар орлыгын җитештерү һәм реализацияләү чыгымнарын каплау өчен субсидияләр | 9 765,0 |
| 10 | Итле токымнан булган нәсел үрчеткеч нәселле үгезләр җитештерү һәм реализацияләү чыгымнарын каплау өчен субсидияләр | 8 171,1 |
| 11 | Балык үрчетү материалы сатып алу чыгымнарын каплау өчен субсидияләр | 4 312,7 |
| 12 | Мөгезле эре терлектән булган бозаулар үрчеме өчен хайваннарны ясалма орлыкландыру операторларына субсидияләр | 28 334,7 |
| 13 | Чиста канлы меңге токымнан булган нәсел атлары һәм юртаклар тренингы һәм аларны сынау чыгымнарын каплау өчен субсидияләр | 10 000,0 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 14 | Авыл хуҗалыгы хайваннарын ясалма орлыкландыруга сатып алынган инструментлар һәм җиһазлар чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр | 16 695,7 |
| 15 | Ясалма орлыкландыру һәм сыек азот ташу өчен сатып алынган махсус автотранспорт чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр | 5 627,9 |
| 16 | Кәҗәләр сатып алу чыгымнарын каплау өчен субсидияләр | 4 709,4 |
| 17 | Йорт куяннары сатып алу чыгымнарын каплау өчен субсидияләр | 2 252,8 |
| 18 | Тарихи татар токымын булдыру өчен атларның ана баш санын сатып алу чыгымнарын каплауга субсидияләр | 2 635,0 |
| 19 | Нәселле атлар сатып алу чыгымнарын каплауга субсидияләр | 21 830,0 |
| 20 | Сөтле токымнан булган нәселле мөгезле эре терлек җитештерү һәм реализацияләү чыгымнарын каплау өчен субсидияләр | 156 667,4 |
| 21 | Үрдәкләр сатып алу чыгымнарын каплау өчен субсидияләр | 2 004,7 |
| 22 | Сөтле токымнан булган нәселле мөгезле эре терлек сатып алу чыгымнарын каплау өчен субсидияләр | 43 487,7 |
| 23 | Дөяләр сатып алу чыгымнарын каплау өчен субсидияләр | 4 005,0 |
| | Барлыгы | 569 293,6 |

F:\KARAR\2015\1045_3.doc

2015 елда нәселле терлекчелеккә булышлык күрсәтү өчен акча бирү тәртибенә 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 31 декабрь, 1045 нче карары редакциясендә)

2015 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең нәселле авыл хуҗалыгы хайваннары сатып алу чыгымнарын каплауга финанслау лимитларын Татарстан Республикасы муниципаль районнары буенча бүлү

| Т/с | Муниципаль район исеме | Субсидияләр лимиты, мең сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Әгерҗе | 5 303,5 |
| 2 | Азнакай | 1 666,5 |
| 3 | Аксубай | 1 602,4 |
| 4 | Актаныш | 1 257,8 |
| 5 | Алексеевск | 6 403,0 |
| 6 | Әлмәт | 2 963,7 |
| 7 | Апас | 872,9 |
| 8 | Арча | 7 750,4 |
| 9 | Әтнә | 705,9 |
| 10 | Баулы | 266,3 |
| 11 | Балтач | 2 010,9 |
| 12 | Бөгелмә | 27,4 |
| 13 | Буа | 353,4 |
| 14 | Югары Ослан | 120,8 |
| 15 | Биектау | 5 001,0 |
| 16 | Чүпрәле | 675,0 |
| 17 | Алабуга | 86,2 |
| 18 | Зәй | 5 152,7 |
| 19 | Зеленодольск | 7 572,6 |
| 20 | Кайбыч | 160,6 |
| 21 | Кама Тамагы | 681,4 |
| 22 | Кукмара | 2 185,9 |
| 23 | Лаеш | 1 757,3 |
| 24 | Лениногорск | 2 282,7 |
| 25 | Мамадыш | 10 933,2 |
| 26 | Менделеевск | 344,3 |
| 27 | Минзәлә | 55,8 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 28 | Мөслим | 20,0 |
| 29 | Түбән Кама | 955,8 |
| 30 | Яңа Чишмә | 133,9 |
| 31 | Нурлат | 119,8 |
| 32 | Питрәч | 1 678,6 |
| 33 | Балык Бистәсе | 1 687,3 |
| 34 | Саба | 8 064,4 |
| 35 | Сарман | 1 399,9 |
| 36 | Тәтеш | 1 195,0 |
| 37 | Тукай | 19,8 |
| 38 | Теләче | 2 247,7 |
| 39 | Чирмешән | 8,6 |
| 40 | Чистай | 763,0 |
| 41 | Ютазы | 767,1 |
| | Барлыгы | 87 254,5 |

2015 елда авыл хуҗалыгы җитештерүен техник һәм технологик модернизацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибенә кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 31 декабрь, 1045 нче карары
редакциясендә)

2015 елда авыл хуҗалыгы җитештерүен техник һәм технологик модернизацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр лимитларын бүлү

| Т/с | Муниципаль районнар исеме | Субсидияләр лимиты барлыгы, мең сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Әгерҗе | 595,9 |
| 2 | Азнакай | 49 444,6 |
| 3 | Аксубай | 3 318,1 |
| 4 | Актаныш | 77 499,7 |
| 5 | Алексеевск | 24 793,1 |
| 6 | Әлки | 63 162,0 |
| 7 | Әлмәт | 22 639,1 |
| 8 | Апас | 3 223,6 |
| 9 | Арча | 37 855,9 |
| 10 | Әтнә | 40 816,0 |
| 11 | Баулы | 8 069,1 |
| 12 | Балтач | 55 497,4 |
| 13 | Бөгелмә | 186 821,7 |
| 14 | Буа | 40 129,8 |
| 15 | Югары Ослан | 7 233,8 |
| 16 | Биектау | 40 162,1 |
| 17 | Чүпрәле | 18 473,1 |
| 18 | Алабуга | 25 379,6 |
| 19 | Зәй | 48 289,4 |
| 20 | Зеленодольск | 37 325,8 |
| 21 | Кайбыч | 1 408,5 |
| 22 | Кама Тамагы | 10 665,6 |
| 23 | Кукмара | 39 942,9 |
| 24 | Лаеш | 45 643,2 |
| 25 | Лениногорск | 33 368,0 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 26 | Мамадыш | 55 495,9 |
| 27 | Менделеевск | 277,1 |
| 28 | Минзәлә | 14 973,0 |
| 29 | Мөслим | 16 012,0 |
| 30 | Түбән Кама | 122 957,8 |
| 31 | Яңа Чишмә | 17 186,7 |
| 32 | Нурлат | 13 600,6 |
| 33 | Питрәч | 24 431,8 |
| 34 | Балык Бистәсе | 18 322,9 |
| 35 | Саба | 57 982,5 |
| 36 | Сарман | 8 627,0 |
| 37 | Спас | 12 522,8 |
| 38 | Тәтеш | 34 193,4 |
| 39 | Тукай | 88 789,9 |
| 40 | Теләче | 6 582,2 |
| 41 | Чирмешән | 3 010,0 |
| 42 | Чистай | 34 819,7 |
| 43 | Ютазы | 11 799,2 |
| Муниципаль районнар буенча барлыгы | | 1 463 342,5 |
| Өстәмә лимит (Төбәк азык-төлек фондын булдыру максатларында тапшырылган ашлык өчен) | | 31 387,4 |
| 44 | Гаилә фермалары | 13 307,6 |
| 45 | Агрохимияләштерү махсуслаштырылган оешмалары һәм бүлекчәләре | 24 268,6 |
| 46 | Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (газ-мотор ягулыгында эшли торган техника өчен) | 47 934,2 |
| 47 | Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (терлекчелек объектларын җиһазландыруга югары технологияле инновацион җиһазлар өчен) | 20 175,9 |
| 48 | Кече эшмәкәрлек субъектлары (махсуслаштырылган һәм технологик җиһазлар, шулай ук махсус автотранспорт өчен) | 29 187,1 |
| 49 | Кече эшмәкәрлек субъектлары (авыл хуҗалыгы продукциясен бүлү, эшкәртү һәм төрү өчен махсуслаштырылган җиһаз өчен) | 20 000,0 |
| 50 | Кулланучылар кооперациясе предприятиеләре | 28 792,4 |
| 51 | Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар | 9 434,4 |
| 52 | Җиләк-җимешләр үстерү һәм эшкәртү эшчәнлеген алып баручы оешмалар | 885,4 |
| 53 | Бәрәңге, ачык һәм ябык грунттагы яшелчәләр үстерү һәм эшкәртү эшчәнлеген алып баручы оешмалар | 50 636,0 |
| 54 | Махсуслаштырылган мелиорация оешмалар һәм бүлекчәләр | 6 440,0 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 55 | Икмәк пешерү сәнәгате предприятиеләре | 54 888,5 |
| 56 | Машина-технология компанияләре | 55 000,0 |
| | Барлыгы | 1 855 680,0 |

F:\KARAR\2015\1045_5.doc

2015 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга мөгезле эре терлектән булган таналарны сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибенә кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 31 декабрь, 1045 нче карары редакциясендә)

2015 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга мөгезле эре терлектән булган таналарны сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирүгә финанслау лимитларын
Татарстан Республикасы муниципаль районнары буенча бүлү

| Т/с | Муниципаль район исеме | Субсидияләр лимиты, мең сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Әгерҗе | 75,0 |
| 2 | Азнакай | 30,0 |
| 3 | Аксубай | 30,0 |
| 4 | Актаныш | 195,0 |
| 5 | Алексеевск | 135,0 |
| 6 | Әлмәт | 15,0 |
| 7 | Арча | 240,0 |
| 8 | Әтнә | 600,0 |
| 9 | Баулы | 120,0 |
| 10 | Балтач | 45,0 |
| 11 | Бөгелмә | 180,0 |
| 12 | Биектау | 180,0 |
| 13 | Чүпрәле | 1770,0 |
| 14 | Алабуга | 15,0 |
| 15 | Зеленодольск | 45,0 |
| 16 | Кайбыч | 720,0 |
| 17 | Кукмара | 360,0 |
| 18 | Лениногорск | 600,0 |
| 19 | Мамадыш | 825,0 |
| 20 | Менделеевск | 30,0 |
| 21 | Минзәлә | 120,0 |
| 22 | Яңа Чишмә | 930,0 |
| 23 | Нурлат | 1215,0 |
| 24 | Балык Бистәсе | 225,0 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 25 | Саба | 345,0 |
| 26 | Теләче | 150,0 |
| 27 | Чирмешән | 645,0 |
| 28 | Чистай | 15,0 |
| Барлыгы | | 9855,0 |

F:\KARAR\2015\1045_6.doc

2015 елда шәхси ярдәмче хуҗалыгы булган гражданнарга савым сыерларын, ана кәҗәләрне һәм бер яшьтән зуррак кәҗәләрне карап тоту буенча чыгымнарның бер өлешен кире кайтаруга субсидияләр бирү тәртибенә 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 31 декабрь, 1045 нче карары редакциясендә)

2015 елда шәхси ярдәмче хуҗалыгы булган гражданнарга савым сыерларын карап тоту буенча чыгымнарның бер өлешен кире кайтару өчен субсидияләр бирүгә финанслау лимитларын Татарстан Республикасы муниципаль районнары буенча бүлү

| Т/с | Татарстан Республикасы муниципаль районы исеме | Субсидияләр лимиты, мең сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Әгерҗе | 6045,0 |
| 2 | Азнакай | 8844,0 |
| 3 | Аксубай | 11001,0 |
| 4 | Актаныш | 14370,0 |
| 5 | Алексеевск | 7059,0 |
| 6 | Әлки | 8163,0 |
| 7 | Әлмәт | 5628,0 |
| 8 | Апас | 6699,0 |
| 9 | Арча | 16980,0 |
| 10 | Әтнә | 8169,0 |
| 11 | Баулы | 5661,0 |
| 12 | Балтач | 16269,0 |
| 13 | Бөгелмә | 2874,0 |
| 14 | Буа | 10194,0 |
| 15 | Югары Ослан | 1395,0 |
| 16 | Биектау | 6876,0 |
| 17 | Чүпрәле | 15189,0 |
| 18 | Алабуга | 1995,0 |
| 19 | Зәй | 5055,0 |
| 20 | Зеленодольск | 5349,0 |
| 21 | Кайбыч | 5223,0 |
| 22 | Кама Тамагы | 4428,0 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 23 | Кукмара | 14214,0 |
| 24 | Лаеш | 1800,0 |
| 25 | Лениногорск | 4026,0 |
| 26 | Мамадыш | 11184,0 |
| 27 | Менделеевск | 1857,0 |
| 28 | Минзәлә | 7410,0 |
| 29 | Мөслим | 10629,0 |
| 30 | Түбән Кама | 4812,0 |
| 31 | Яңа Чишмә | 6384,0 |
| 32 | Нурлат | 12693,0 |
| 33 | Питрәч | 3363,0 |
| 34 | Балык Бистәсе | 7938,0 |
| 35 | Саба | 7848,0 |
| 36 | Сарман | 7152,0 |
| 37 | Спас | 8949,0 |
| 38 | Тәтеш | 5661,0 |
| 39 | Тукай | 4779,0 |
| 40 | Теләче | 5712,0 |
| 41 | Чирмешән | 5451,0 |
| 42 | Чистай | 9822,0 |
| 43 | Ютазы | 4800,0 |
| | Барлыгы | 319950,0 |

---

2015 елда шәхси ярдәмче хуҗалыгы булган гражданнарга савым сыерларын, ана кәҗәләрне һәм бер яшьтән зуррак кәҗәләрне карап тоту буенча чыгымнарның бер өлешен кире кайтаруга субсидияләр бирү тәртибенә 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының
2015 ел, 31 декабрь, 1045 нче карары редакциясендә)

2015 елда шәхси ярдәмче хуҗалыгы булган гражданнарга ана кәҗәләрне һәм бер яшьтән зуррак кәҗәләрне карап тоту буенча чыгымнарның бер өлешен кире кайтару өчен субсидияләр бирүгә финанслау лимитларын Татарстан Республикасы муниципаль районнары буенча бүлү

| Т/с | Татарстан Республикасы муниципаль районы исеме | Субсидияләр лимиты, мең сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Әгерҗе | 695,0 |
| 2 | Азнакай | 780,0 |
| 3 | Аксубай | 976,0 |
| 4 | Актаныш | 934,0 |
| 5 | Алексеевск | 451,0 |
| 6 | Әлки | 555,0 |
| 7 | Әлмәт | 1314,0 |
| 8 | Апас | 571,0 |
| 9 | Арча | 993,0 |
| 10 | Әтнә | 266,0 |
| 11 | Баулы | 487,0 |
| 12 | Балтач | 954,0 |
| 13 | Бөгелмә | 705,0 |
| 14 | Буа | 939,0 |
| 15 | Югары Ослан | 457,0 |
| 16 | Биектау | 906,0 |
| 17 | Чүпрәле | 620,0 |
| 18 | Алабуга | 531,0 |
| 19 | Зәй | 924,0 |
| 20 | Зеленодольск | 502,0 |
| 21 | Кайбыч | 380,0 |
| 22 | Кама Тамагы | 350,0 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 23 | Кукмара | 1019,0 |
| 24 | Лаеш | 705,0 |
| 25 | Лениногорск | 748,0 |
| 26 | Мамадыш | 848,0 |
| 27 | Менделеевск | 369,0 |
| 28 | Минзәлә | 606,0 |
| 29 | Мөслим | 486,0 |
| 30 | Түбән Кама | 1211,0 |
| 31 | Яңа Чишмә | 260,0 |
| 32 | Нурлат | 923,0 |
| 33 | Питрәч | 684,0 |
| 34 | Балык Бистәсе | 512,0 |
| 35 | Саба | 684,0 |
| 36 | Сарман | 912,0 |
| 37 | Спас | 447,0 |
| 38 | Тәтеш | 748,0 |
| 39 | Тукай | 1181,0 |
| 40 | Теләче | 363,0 |
| 41 | Чирмешән | 646,0 |
| 42 | Чистай | 416,0 |
| 43 | Ютазы | 246,0 |
| | Барлыгы | 29304,0 |

F:\KARAR\2015\1045_8.doc

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 26 февраль, 120 нче карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 31 декабрь, 1045 нче карары редакциясендә)

2015 елда крестьян (фермер) хуҗалыкларына ана кәҗәләрне һәм бер яшьтән зуррак кәҗәләрне карап тоту чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2015 елда крестьян (фермер) хуҗалыкларына, шәхси эшмәкәрләрне дә кертеп (алга таба – хуҗалыклар), ана кәҗәләрне һәм бер яшьтән зуррак кәҗәләрне карап тоту чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр бирү «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Субсидия бирү максатлары – кәҗәләрнең баш санын саклау, терлекчелек продукциясе җитештерүне арттыру һәм шул нигездә авыл халкының эш белән тәэмин ителешен һәм керемнәрен арттыру.

4. Субсидияләр хуҗалыкларга ана кәҗәләрне һәм бер яшьтән зуррак кәҗәләрне карап тоту чыгымнарының бер өлешен каплау өчен, алар нигезендә 3-фермер «Терлекчелек продукциясе җитештерү һәм терлекнең баш саны турында мәгълүматлар» (алга таба – мәгълүматлар) формасы буенча дәүләт статистика күзәтүе органнарына хисаплар төзелә торган мәгълүматларда чагылдырылган ана кәҗәләр һәм бер яшьтән зуррак кәҗәләр санына пропорциональ рәвештә бирелә.

5. Субсидияләр хуҗалыкларның дәүләт теркәвенә алынган булуы һәм Татарстан Республикасы территориясендә җитештерү эшчәлеген гамәлгә ашыруы шартында бирелә.

Субсидияләр ябылу стадиясендә булган яки акчасыз (банкрот) дип танылган хуҗалыкларга бирелми.

6. Субсидияләр хуҗалыкларга бер тапкыр, бер баш ана кәҗәгә һәм бер яшьтән зуррак кәҗәгә 1,0 мең сум исәбеннән чыгып бирелә.

7. Субсидия алу өчен хуҗалыклар Министрлыкның муниципаль районнардагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә (алга таба – Идарәләр) түбәндәге документларны кертә:

субсидиянең суммасын, үзләренең түләү реквизитларын һәм почта адресын, шулай ук ана кәҗәләр һәм бер яшьтән зуррак кәҗәләрнең баш санын күрсәтеп, ирекле формада субсидия бирү турында гариза;

физик затны шәхси эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алу турындагы шаһәдатнамә яки крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алу турындагы шаһәдатнамә күчермәсен;

соңгы хисап датасына мәгълүматлар;

2016 елның 31 декабренә кадәр кәҗәләрнең баш санын саклау турында ирекле формада хуҗалык йөкләмәсе;

Министрлык раслаган форма буенча белешмә-исәп-хисап.

8. Ана кәҗәләр һәм бер яшьтән зуррак кәҗәләр кабул ителгән йөкләмәнең вакыты чыкканга кадәр күпләп үлгән очракта яисә аларны авыру сәбәпле суйган очракта, хуҗалыклар Идарәләргә ветеринария белешмәләрен һәм терлекне бракка чыгару актларын кертәләр.

9. Идарәләр:

субсидияләр бирү турындагы гаризаларны алар кертелгән көндә журналда терки, журналның бит саннары куелган, ул тегелгән һәм мөһер белән расланган булырга тиеш;

гариза теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә:

кертелгән документларны әлеге Тәртипнең 5 нче һәм 7 нче пунктлары нигезендә карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту хакында карар кабул итә;

алда әйтелгән документлар нигезендә Министрлык раслаган форма буенча Татарстан Республикасы муниципаль районына бирелергә тиешле субсидияләр турында җыелма белешмә-исәп-хисаплар тутыра һәм аларны Министрлыкка кертә.

Документларның тулы булмаган комплектын кертү яки аларның әлеге Тәртип таләпләренә туры килмәве субсидия бирүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Субсидия бирүдән баш тарткан очракта, Идарәләр субсидия бирү турындагы гаризаны теркәгәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә хуҗалыкка баш тарту турында хәбәрнамә җибәрәләр.

10. Министрлык хуҗалыклар белән Министрлык раслаган форма буенча субсидия бирү турында килешүләр төзи.

11. Министрлык бюджет акчасы белән баш эш итүче була һәм бюджет акчасын Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган үз шәхси исәбеннән, Идарәләр тарафыннан Министрлыкка кертелгән җыелма белешмә-исәп-хисаплар нигезендә, әлеге Тәртипнең 9 нчы пунктындагы өченче абзацта күрсәтелгән вакыт чыкканнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә хуҗалыкларның хисап исәпләренә күчерүне гамәлгә ашыра.

12. Бирелгән субсидияләр әлеге Тәртип белән билгеләнгән аларны бирү шартларын бозу һәм (яки) субсидияләр алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар кертү фактларын ачыклау буенча Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган алтмыш көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш.

13. Субсидияләр бирү турындагы килешүләр белән күздә тотылган

очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр 2016 елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш.

14. Әлеге Тәртипнең 12 нче һәм 13 нче пунктларында күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемена үз ирекләре белән кайтарудан баш тартсалар, ул законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

15. Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы субсидия алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүләрен тикшерүне Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашыра.

16. Идарәләр Министрлыкка һәм хуҗалыклар кертә торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә аларның вазыйфаи затларына һәм җитәкчеләренә йөкләнә.

17. Бюджет акчасыннан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

---

F:\KARAR\2015\1045_9.doc

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 26 февраль, 120 нче карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 31 декабрь, 1045 нче карары редакциясендә)

## 2015 елда авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына матди-техник базаны үстерүгә грантлар бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2015 елда Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының (алга таба – Министрлык) авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына матди-техник базаны үстерүгә грантлары (алга таба – грант) рәвешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү механизмын билгели.

2. Грантлар бирү «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына матди-техник базаны үстерү өчен грант ярдәме күрсәтүгә федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2015 ел, 24 июнь, 623 нче карары белән расланган Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына матди-техник базаны үстерү өчен грант ярдәме күрсәтүгә федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрендә кулланыла торган төшенчә мәгънәсендә авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары грантлар алучылар булып тора.

4. Грантлар кооперативларга түбәндәге максатларга бирелә:

авыл хуҗалыгы хайваннарын һәм кош-кортларын, балык һәм аквакультураны әзерләү, саклау, эшкәртү, аралау, чалу, беренчел эшкәртү буенча, сөт, ит, кошлар, бәрәңге, гөмбә, яшелчәләр, җимешләр һәм җиләкләрне, шул исәптән кыргый җимешләр һәм җиләкләрне суыту буенча һәм авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аны эшкәртү продуктларын реализацияләүгә әзерләү буенча производство объектларын төзү, төзекләндерү яки модернизацияләү;

авыл хуҗалыгы хайваннарын һәм кош-кортларын, балык һәм аквакультураны әзерләү, саклау, эшкәртү, аралау, чалу, беренчел эшкәртү өчен, сөт, ит, кошлар, бәрәңге, гөмбә, яшелчәләр, җимешләр һәм җиләкләрне, шул исәптән кыргый җимешләр һәм җиләкләрне суыту өчен, авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аны эшкәртү продуктларын реализацияләүгә, төяүгә һәм бушатуга әзерләү өчен, чыгарыла (җитештерелә, эшкәртелә) торган продукциянең сыйфатын һәм

куркынычсызлыгын производство тикшерүе буенча лабораторияләрне җиһазландыру өчен һәм Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә дәүләт ветеринария-санитария экспертизасы үткәрү (авыл хуҗалыгы продукциясе сыйфатына лаборатория анализы үткәрү өчен җиһаз сатып алу) өчен каралган производство объектларына җиһазлар һәм техника сатып алу һәм аларны монтажлау;

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аны эшкәртү продуктларын транспортлау өчен һәм транспортта күчерү һәм реализацияләү вакытында аларның сакланышын тәэмин итү өчен махсуслаштырылган транспорт, фургоннар, тагылмалар, ярымтагылмалар, вагоннар, контейнерлар сатып алу;

авыл хуҗалыгы хайваннарын һәм кош-кортларын, балык һәм аквакультураны саклау, эшкәртү, аралау, чалу, беренчел эшкәртү өчен, сөт, ит, кошлар, бәрәңге, гөмбә, яшелчәләр, җимешләр һәм җиләкләрне, шул исәптән кыргый җимешләр һәм җиләкләрне суыту өчен, авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аны эшкәртү продуктларын реализацияләүгә, төяүгә, бушатуга һәм транспортлауга әзерләү өчен җиһазлар һәм техник чаралар лизингы шартнамәләре буенча керемнәрнең бер өлешен түләү (лизинг предметларының гомуми кыйммәтенең 8 процентыннан да артык түгел).

5. Министрлык боерыгы белән раслана торган авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына матди-техник базаны үстерүгә грантлар бирү турындагы нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) буенча грантлар бирүгә гаризаларны конкурс нигезендә сайлап алуда җиңү Грант бирү шарты булып тора.

6. Конкурс нигезендә сайлап алу критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

кимендә 3 еллык вакытка авыл хуҗалыгы продукциясен әзерләүне һәм (яки) эшкәртүне һәм (яки) сатуны арттыруны күздә тоткан кооперативны үстерү программасы булу;

кооперативның матди-техник базасын үстерүгә чыгымнар планы (алга таба– Чыгымнар планы) булу;

Чыгымнар планында күрсәтелгән чыгымнарның һәр статьясы кыйммәтенең кимендә 40 процентын үз акчаң һәм (яки) заемга алынган акчалар исәбеннән түләү;

грантның һәр 10 млн.сумына кимендә 6 даими яңа эш урыннары булдыру;

грантны алган көннән кимендә 5 ел финанс-хуҗалык эшчәнлеген алып бару.

7. Конкурс нигезендә сайлап алуда катнашу өчен кооперативлар тарафыннан Министрлыкка кертелә торган документлар Нигезләмәдә билгеләнә. Әлеге документларны карап тикшерү, грантлар бирүгә гаризаларны кабул итү вакыты чыкканнан соң, эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көн эчендә Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Грант максатчан билгеләнештә була, һәм грант алучы аннан әлеге Тәртиптә каралмаган максатларда файдалана алмый.

8. Грантның максималь күләме бер авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативына күп дигәндә 21 млн.сум һәм Чыгымнар планында күрсәтелгән чыгымнарның күп дигәндә 60 процентын тәшкил итә.

Билгеле бер авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативына бирелә торган грант күләме, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының үз акчаларын һәм

әлеге Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән максатларга Чыгымнар планын исәпкә алып, Министрлык тарафыннан төзелә торган конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

9. Грант Министрлык һәм конкурста җиңүче арасында төзелгән грант бирү турындагы шартнамә (алга таба – Шартнамә) нигезендә, Шартнамәне төзегән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә, финанслау лимитлары булган очракта бирелә.

Шартнамәдә түбәндәге нигезләмәләр күздә тотыла:

грантның максатчан билгеләнеше;

кооперативны үстерү юнәлеше;

грант күләме;

грант бирү нәтиҗәлелегенең күрсәткечләре мәгънәләре;

грант аларны финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында Министрлыкраслаган форма буенча хисаплылык, шулай ук грант бирү нәтиҗәлелегенең күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү хакында хисап тапшыру тәртибе һәм вакытлары;

грант алучының грант бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүләр үткәрүгә ризалык;

алган көннән соң 18 ай эчендә файдаланылмаган грантларны кире кайтару тәртибе;

Шартнамә нигезләмәләрен бозган өчен җаваплылык.

10. Министрлык бюджет акчасы белән баш эш итүче була һәм грантны Шартнамәдә билгеләнгән вакытта Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган үз шәхси исәбеннән грант алучыларның хисап исәпләренә күчерүне гамәлгә ашыра.

11. Грант алучылар Министрлык билгеләгән вакытта һәм форма нигезендә Министрлыкка грантлар аларны финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнар турында агымдагы һәм йомгак хисапларны, шулай ук грант бирү нәтиҗәлелегенең күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү хакында хисаплар кертә.

12. Бирелгән грантлар әлеге Тәртип белән билгеләнгән аларны бирү шартларын бозу, грантлардан масатчан файдаланмау һәм (яки) грантлар алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар кертү фактларын ачыклау буенча Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган алтмыш көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемено кире кайтарылырга тиеш.

13. Шартнамә белән күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган грантлар хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемено грант алучы тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

14. Әлеге Тәртипнең 12 нче һәм 13 нче пунктларында күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемено үз ирекләре белән кайтарудан баш тартсалар, ул законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

15. Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы грант алучыларның грант бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүләрен

тикшерүне Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашыра.

16. Грантны максатчан һәм нәтиҗәле үзләштерү, шулай ук конкурста катнашуга кертелгән документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә грант алучыга йөкләнә.

17. Бюджет акчасыннан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

---

F:\KARAR\2015\1045_10.doc

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 26 февраль, 120 нче карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 31 декабрь, 1045 нче карары редакциясендә)

2015 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплекслары (сөт фермалары) төзү эшләрен башкаруга бәйле булган чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2015 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплекслары (сөт фермалары) төзү эшләрен башкаруга бәйле булган чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр бирү «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Савым сыерларының баш санын арттыру өчен икътисадый һәм технологик шартлар тудыру субсидия бирү шарты булып тора.

4. Субсидияләр ябылу стадиясендә булган яки акчасыз (банкрот) дип танылган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бирелми.

5. Субсидияләр сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплекслары (сөт фермалары) төзү эшләрен башкаруга бәйле булган чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә – башкарылган эшләр күләменең 80 проценты исәбеннән чыгып бирелә.

6. Субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Министрлыкка түбәндәге документларны кертә:

үзләренең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, ирекле формада субсидия бирү турында гариза;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан расланган сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплекслары (сөт фермалары) төзүгә җыелма смета исәп-хисабы һәм локаль смета исәп-хисабы;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан расланган эшләр башкаруга подряд шартнамәләре;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан расланган КС-2 статистика формасы буенча эшләрне кабул итү турында акт;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан расланган КС-3 статистика формасы буенча башкарылган эшләр һәм чыгымнар кыйммәте турында белешмә;

хуҗалык ысулы белән эшләр башкарганда, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан расланган КС-2 статистика формасы буенча эшләрне кабул итү турында акт һәм КС-3 статистика формасы буенча башкарылган эшләр һәм чыгымнар кыйммәте турында белешмә;

Министрлык раслаган форма буенча субсидияләр алу өчен белешмә-исәп-хисаплар.

7. Министрлык:

кертелгән көннән бер көн эчендә субсидия бирү турындагы гаризаларны терки;

гаризаны теркәгән көннән 20 көн эчендә кертелгән документларны әлеге Тәртипнең 6 нчы пункты нигезендә карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту хакында карар кабул итә.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

документларның тулы булмаган комплектын кертү яки аларның әлеге Тәртип таләпләренә туры килмәве;

бюджет йөкләмәләре лимитыннан калган акча булмау.

8. Министрлык авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре белән Министрлык раслаган форма буенча субсидия бирү турында килешүләр төзи.

9. Министрлык бюджет акчасы белән баш эш итүче була һәм субсидияләрне Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган үз шәхси исәбеннән, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан Министрлыкка кертелгән белешмә-исәп-хисаплар нигезендә, әлеге Тәртипнең 7 нче пунктындагы өченче абзацта күрсәтелгән вакыт чыкканнан соң биш көн эчендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең хисап исәпләренә күчерүне гамәлгә ашыра.

10. Бирелгән субсидияләр әлеге Тәртип белән билгеләнгән аларны бирү шартларын бозу, субсидияләрдән максатчан файдаланмау һәм (яки) субсидияләр алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар кертү фактларын ачыклау буенча Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемнә кире кайтарылырга тиеш.

11. Субсидияләр бирү турындагы килешүләр белән күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемнә субсидия алучылар тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

12. Әлеге Тәртипнең 10 нчы һәм 11 нче пунктларында күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемнә үз ирекләре белән кайтарудан баш тартсалар, ул законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

13. Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы субсидия алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүләрен тикшерүне Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашыра.

14. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан Министрлыкка кертелә торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә аларның җитәкчеләренә һәм вазыйфаи затларына йөкләнә.

15. Бюджет акчасыннан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 26 февраль, 120 нче карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 31 декабрь, 1045 нче карары редакциясендә)

2015 елда «2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында итле терлекчелекне үстерү» икътисадый әһәмияттәге ведомство максатчан төбәк программасын тормышка ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип «2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында итле терлекчелекне үстерү» икътисадый әһәмияттәге ведомство максатчан төбәк программасын (алга таба – Программа) тормышка ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (алга таба – Программада катнашучылар) субсидияләр бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр бирү «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Программада катнашучыларның үз милкендә һәм (яки) аренда шартларында махсуслаштырылган итле яки җирле токымнан мөгезле эре терлекнең (алга таба – итле токымнан булган мөгезле эре терлек) күп баш саны булу субсидия бирү шарты булып тора.

Субсидияләр ябылу стадиясендә булган яки акчасыз (банкрот) дип танылган Программада катнашучыларга бирелми.

4. Субсидия бирү максатлары булып түбәндәгеләр тора:

2015 елның 31 декабре хәленә карата итле токымнан булган мөгезле эре терлекнең баш санын арттыруны тәэмин итү буенча икътисадый һәм технологик шартлар тудыру;

ит җитештерү күләмнәрен арттыру.

5. Авыл хуҗалыгы җитештерүенең төп эшчәнлек төре буларак итле токымнан булган мөгезле эре терлек үрчетү эшчәнлеген гамәлгә ашыру субсидияләр алуга Программада катнашучыларны сайлап алу критерие булып тора.

6. Субсидияләр Программада катнашучыларга түбәндәгеләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә:

а) итле токымнан булган мөгезле эре терлек үрчетү буенча фермалар һәм фидлотлар (терлекне симертү өчен ачык мәйданчыклар) төзү, төзекләндерү һәм

модернизацияләүгә, аларга керү юлларын һәм электр тапшыру, су белән тәэмин итү линияләрен үткәрүгә чыгымнарның бер өлешен каплау өчен – Программаны тормышка ашыра башлаган елдан алып башкарылган эшләр күләменең 55 проценты исәбеннән чыгып;

б) итле токымнан булган мөгезле эре терлек үрчетү өчен сатып алынган технология җайланмалары һәм азык әзерләү техникасына чыгымнарның бер өлешен каплау өчен – Программаны тормышка ашыра башлаган елдан алып сатып алынган җайланмалар һәм азык әзерләү техникасы кыйммәтенең 55 проценты исәбеннән чыгып.

7. Әлеге Тәртипнең 6 нчы пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен, Программада катнашучылар Министрлыкка түбәндәге документларны кертә:

үзләренең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, ирекле формада субсидия бирү турында гариза;

фермалар һәм фидлотлар төзү, төзекләндерү һәм модернизацияләүгә җыелма смета исәп-хисабы күчермәсен;

фермалар һәм фидлотлар төзү, төзекләндерү һәм модернизацияләүгә подряд шартнамәсе күчермәсен;

«Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт» дигән КС-2 статистика формасы буенча белешмә;

«Башкарылган эшләр һәм чыгымнар кыйммәте турында белешмә» дигән КС-3 статистика формасы буенча белешмә;

хуҗалык ысулы белән эшләр башкарганда, «Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт» дигән КС-2 һәм «Башкарылган эшләр һәм чыгымнар кыйммәте турында белешмә» дигән КС-3 статистика формалары буенча белешмәләр;

банк тарафыннан таныкланган башкарылган эшләр өчен түләүне дәлилле торган түләү йөкләмәсе;

Министрлык раслаган форма буенча субсидияләр алу өчен белешмә-исәп-хисаплар.

Кертелгән документларның күчермәләре Программада катнашучылар тарафыннан таныклана.

8. Әлеге Тәртипнең 6 нчы пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен, Программада катнашучылар Министрлыкка түбәндәге документларны кертә:

үзләренең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, ирекле формада субсидия бирү турында гариза;

технология җайланмалары яки азык әзерләү техникасы кайтарту (сату-алу) шартнамәсе, товар йөкнамәсе, ОС-1 формасы буенча кабул итү-тапшыру акты күчермәсен;

банк тарафыннан таныкланган технология җайланмалары яки азык әзерләү техникасы өчен түләүне дәлилле торган түләү йөкләмәсе;

җайланма яки техника паспорты (әйбернең паспорты) күчермәсе;

Министрлык раслаган форма буенча субсидияләр алу өчен белешмә-исәп-хисаплар.

Кертелгән документларның күчермәләре Программада катнашучылар тарафыннан таныклана.

9. Министрлык:

кертелгән көннән бер көн эчендә субсидия бирү турындагы гаризаларны терки;

гаризаны теркәгән көннән 20 көн эчендә кертелгән документларны әлеге Тәртипнең 7 нче һәм 8 нче пунктлары нигезендә карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту хакында карар кабул итә.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

документларның тулы булмаган комплектын кертү яки аларның әлеге Тәртип таләпләренә туры килмәве;

бюджет йөкләмәләре лимитыннан калган акча булмау.

10. Министрлык Программада катнашучылар белән Министрлык раслаган форма буенча субсидия бирү турында килешүләр төзи.

11. Министрлык бюджет акчасы белән баш эш итүче була һәм акчаны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган үз шәхси исәбеннән, Министрлык раслаган субсидияләр бирү өчен белешмә-исәп-хисаплар нигезендә, әлеге Тәртипнең 9 нчы пунктындагы өченче абзацта күрсәтелгән вакыт чыкканнан соң биш көн эчендә Программада катнашучыларның хисап исәпләренә күчерүне гамәлгә ашыра.

12. Бирелгән субсидияләр әлеге Тәртип белән билгеләнгән аларны бирү максатларын һәм шартларын бозу, субсидияләрдән максатчан файдаланмау һәм (яки) субсидияләр алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар кертү фактларын ачыклау буенча Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

13. Субсидияләр бирү турындагы килешүләр белән күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемenә Программада катнашучылар тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

14. Әлеге Тәртипнең 12 нче һәм 13 нче пунктларында күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемenә үз ирекләре белән кайтарудан баш тартсалар, ул законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

15. Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы субсидия алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүләрен тикшерүне Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашыра.

16. Программада катнашучылар тарафыннан Министрлыкка кертелә торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә аларның җитәкчеләренә һәм вазыйфаи затларына йөкләнә.

17. Бюджет акчасыннан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

---

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 26 февраль, 120 нче карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 31 декабрь, 1045 нче карары редакциясендә)

2015 елда «2015 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү» икътисадый әһәмияттәге ведомство максатчан төбәк программасын тормышка ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип «2015 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү» икътисадый әһәмияттәге ведомство максатчан төбәк программасын (алга таба – Программа) тормышка ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (алга таба – Программада катнашучылар) субсидияләр бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр бирү «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Программада катнашучыларның үз милкендә һәм (яки) аренда шартларында җитен чәчүлекләре биләгән җир кишәрлекләре булу субсидияләр бирү шарты булып тора.

Субсидияләр ябылу стадиясендә булган яки акчасыз (банкрот) дип танылган Программада катнашучыларга бирелми.

4. Җитен җитештерү һәм эшкәртү күләмнәрен арттыру өчен икътисадый һәм технологик шартлар тудыру субсидия бирү максаты булып тора.

5. Авыл хуҗалыгы җитештерүенең төп эшчәнлек төре буларак җитенне үстерү һәм (яки) беренчел эшкәртү эшчәнлеген гамәлгә ашыру субсидияләр алуга Программада катнашучыларны сайлап алу критерие булып тора.

6. Субсидияләр Программада катнашучыларга түбәндәгеләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә:

а) җитенне беренчел эшкәртү объектларын төзү, төзекләндерү һәм модернизацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен – Программаны тормышка ашыра башлаган елдан алып башкарылган эшләр күләменең 23 проценты исәбеннән чыгып;

б) җитенне беренчел эшкәртү объектлары өчен сатып алынган технология җайланмалары, автотранспорт һәм авыл хуҗалыгы техникасына чыгымнарның бер

өлешен каплау өчен – Программаны тормышка ашыра башлаган елдан алып сатып алынган җайланмалар күләменең 23 проценты исәбеннән чыгып;

в) җитен җитештерү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен – җитен эшкәртү заводына тапшырылган бер тонна җитен өчен 4 600 сум исәбеннән чыгып (сүскә күчергәндә).

7. Әлеге Тәртипнең 6 нчы пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен, Программада катнашучылар Министрлыкка түбәндәге документларны кертә:

үзләренең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, ирекле формада субсидия бирү турында гариза;

җитенне беренчел эшкәртү объектларын төзү, төзекләндерү һәм модернизацияләүгә җыелма смета исәп-хисабы күчермәсен;

җитенне беренчел эшкәртү объектларын төзү, төзекләндерү һәм модернизацияләүгә подряд шартнамәсе күчермәсен;

«Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт» дигән КС-2 статистика формасы буенча белешмә;

«Башкарылган эшләр һәм чыгымнар кыйммәте турында белешмә» дигән КС-3статистика формасы буенча белешмә;

хуҗалык ысулы белән эшләр башкарганда, «Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт» дигән КС-2 һәм «Башкарылган эшләр һәм чыгымнар кыйммәте турында белешмә» дигән КС-3 статистика формалары буенча белешмәләр;

банк тарафыннан таныкланган башкарылган эшләр өчен түләүне дәлилли торган түләү йөкләмәсе;

Министрлык раслаган форма буенча субсидияләр алу өчен белешмә-исәп-хисаплар.

Кертелгән документларның күчермәләре Программада катнашучылар тарафыннан таныклана.

8. Әлеге Тәртипнең 6 нчы пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен, Программада катнашучылар Министрлыкка түбәндәге документларны кертә:

үзләренең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, ирекле формада субсидия бирү турында гариза;

җитенне беренчел эшкәртү объектлары өчен технология җайланмалары, автотранспорт һәм авыл хуҗалыгы техникасы кайтарту шартнамәләре күчермәләре;

товар-транспорт йөкнамәләре;

ОС-1 формасы буенча җайланмаларны кабул итү-тапшыру акты;

технология җайланмалары яки азык әзерләү техникасы кайтарту (сату-алу) шартнамәсе, товар йөкнамәсе күчермәсен;

банк тарафыннан таныкланган җитенне беренчел эшкәртү объектлары өчен технология җайланмалары, автотранспорт һәм авыл хуҗалыгы техникасы өчен түләүне дәлилли торган түләү йөкләмәләре;

Министрлык раслаган форма буенча субсидияләр алу өчен белешмә-исәп-хисаплар.

Кертелгән документларның күчермәләре Программада катнашучылар тарафыннан таныклана.

9. Әлеге Тәртипнең 6 нчы пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен, Программада катнашучылар Министрлыкка түбәндәге документларны кертә:

үзләренең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, ирекле формада субсидия бирү турында гариза;

талкынмаган җитен кайтарту шартнамәләре;

товар йөкнамәләре реестры;

Министрлык раслаган форма буенча субсидияләр алу өчен белешмә-исәп-хисаплар.

Кертелгән документларның күчермәләре Программада катнашучылар тарафыннан таныклана.

10. Министрлык:

кертелгән көннән бер көн эчендә субсидия бирү турындагы гаризаларны бит саннары куелган, беркетелгән һәм мөһер белән расланган булырга тиешле журналда терки;

гаризаны теркәгән көннән 20 көн эчендә кертелгән документларны әлеге Тәртипнең 7 – 9 нчы пунктлары нигезендә карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту хакында карар кабул итә.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

документларның тулы булмаган комплектын кертү яки аларның әлеге Тәртип таләпләренә туры килмәве;

бюджет йөкләмәләре лимитыннан калган акча булмау.

11. Министрлык Программада катнашучылар белән Министрлык раслаган форма буенча субсидия бирү турында килешүләр төзи.

12. Министрлык бюджет акчасы белән баш эш итүче була һәм акчаны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган үз шәхси исәбеннән, Министрлык раслаган субсидияләр бирү өчен белешмә-исәп-хисаплар нигезендә, әлеге Тәртипнең 10 нчы пунктындагы өченче абзацта күрсәтелгән вакыт чыкканнан соң биш көн эчендә Программада катнашучыларның хисап исәпләренә күчерүне гамәлгә ашыра.

13. Бирелгән субсидияләр әлеге Тәртип белән билгеләнгән аларны бирү максатларын һәм шартларын бозу, субсидияләрдән максатчан файдаланмау һәм (яки) субсидияләр алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар кертү фактларын ачыклау буенча Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш.

14. Субсидияләр бирү турындагы килешүләр белән күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемена Программада катнашучылар тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

15. Әлеге Тәртипнең 13 нче һәм 14 нче пунктларында күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемена үз ирекләре белән кайтарудан баш тартсалар, ул законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

16. Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы субсидия алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүләрен тикшерүне Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашыра.

17. Программада катнашучылар тарафыннан Министрлыкка кертелә торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә аларның җитәкчеләренә һәм вазыйфаи затларына йөкләнә.

18. Бюджет акчасыннан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

F:\KARAR\2015\1045_13.doc

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 26 февраль, 120 нче карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 31 декабрь, 1045 нче карары редакциясендә)

## 2015 елда сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) төзү һәм (яки) модернизацияләү өчен турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш (алга таба – авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре), сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) төзү һәм (яки) модернизацияләү өчен турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр бирү «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Субсидияләр алуга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрен сайлап алу критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

а) сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) төзү өчен турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау:

төп эшчәнлек төре – авыл хуҗалыгы җитештерүе, сөтчелек юнәлешендәге мөгезле эре терлек үрчетү;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең милек хокукында булган, кимендә 400 баш сыердан торган, төзелгән сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплекслары (сөт фермалары) булу;

б) сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) модернизацияләү өчен турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау:

төп эшчәнлек төре – авыл хуҗалыгы җитештерүе, сөтчелек юнәлешендәге мөгезле эре терлек үрчетү;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең милек хокукында булган, кимендә 200 баш сыердан торган, модернизацияләнгән сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплекслары (сөт фермалары) булу.

4. Төзелгән һәм (яки) модернизацияләнгән сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплекслары (сөт фермалары), төп рөхсәт итү документлары һәм тоташтыруның техник шартлары белән расланып, күрсәтелгән проект куәтенең 100

проценты күләмендә җылылык, энергия һәм су ресурслары белән тәэмин ителгән булырга тиеш.

5. Әлеге Тәртип нигезендә субсидияләр алу максатларында терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) модернизацияләү, юнәлеш кысаларында барлык чараларны үтәү шарты белән, түбәндәге ике юнәлешнең берсе буенча гамәлгә ашырылырга тиеш:

а) сөтне тоту, саву, кабул итү һәм (яки) беренчел эшкәртү системалары җайланмаларын модернизацияләү:

сөт саву җайланмаларын җиһазландыру һәм (яки) алыштыру;

сөт продукциясен суытып эшкәртү һәм саклауны кертеп, сөтне кабул итү һәм (яки) беренчел эшкәртү җайланмаларын җиһазландыру һәм (яки) алыштыру;

сөтне тоту буенча яңа технологиягә җайлаштырып бинаны планлаштыруны үзгәртү;

б) азык әзерләү һәм тирес чыгару җайланмаларын модернизацияләү:

азык әзерләү һәм бүлеп бирү җайланмаларын җиһазландыру һәм (яки) алыштыру;

тирес чыгару җайланмаларын җиһазландыру һәм (яки) алыштыру.

6. Субсидияләр ябылу стадиясендә булган яки акчасыз (банкрот) дип танылган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бирелми.

7. Төзелгән һәм модернизацияләнгән сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплексларында (сөт фермаларында) сөтнең продуктивлыгын тәэмин итү субсидия бирү максаты булып тора.

8. Субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

төзелгән һәм модернизацияләнгән сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплексларында (сөт фермаларында) сөт җитештерү буенча проектның куәтлелегенә ирешү – аларны эксплуатациягә кертү вакытыннан алып 2 елдан да соңга калмыйча;

төзелгән һәм модернизацияләнгән сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплексларында (сөт фермаларында) планлаштырыла торган сөтнең продуктивлыгы дәрәҗәсе 1 елга бер сыерга ким дигәндә 6 000 килограмм.

9. Субсидияләр алар буенча төзелеш һәм (яки) модернизацияләү субсидия бирелә торган елга кадәр булган елның 1 гыйнварыннан алып башланган сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) төзү һәм (яки) модернизацияләү өчен турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен – өстәмә кыйммәткә салымны һәм проект-тикшерену эшләренә чыгымнарны исәпкә кертмәгәндә, смета кыйммәтенең 1,06 проценты исәбеннән чыгып бирелә, ләкин объектның иң чик кыйммәтеннән артык түгел.

Объектның иң чик кыйммәте Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган объект куәте берәмлеге кыйммәтенең иң чик мәгънәсеннән чыгып билгеләнә.

Күтәрелгән туры чыгымнарның бер өлешен каплау объектны кабул итү актын тапшырганнан соң гамәлгә ашырыла.

10. Субсидияләр алу өчен, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Министрлыкка түбәндәге документларны кертә:

үзләренең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, ирекле формада субсидия бирү турында гариза;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган төзелеш һәм модернизацияләүгә җыелма смета исәп-хисабы күчермәсен;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган проект документлары һәм инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләре дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе күчермәсен;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган объект төзүгә рөхсәтнамә күчермәсен;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган сөтчелек юнәлешендәге терлекчелек комплекслары (сөт фермалары) төзү һәм модернизацияләүгә подряд шартнамәсе күчермәсен;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган «Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт» дигән КС-2 статистика формасы буенча белешмәләр күчермәләрен;

«Башкарылган эшләр һәм чыгымнар кыйммәте турында белешмә» дигән КС-3 статистика формасы буенча белешмәләр күчермәләрен;

хуҗалык ысулы белән эшләр башкарганда, «Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт» дигән КС-2 һәм «Башкарылган эшләр һәм чыгымнар кыйммәте турында белешмә» дигән КС-3 статистика формалары буенча белешмәләр күчермәләрен;

банк тарафыннан таныкланган башкарылган эшләр өчен түләүне дәлилли торган түләү йөкләмәсе;

Министрлык раслаган форма буенча субсидияләр алу өчен белешмә-исәп-хисаплар.

11. Министрлык:

кертелгән көннән бер көн эчендә субсидия бирү турындагы гаризаларны бит саннары куелган, беркетелгән һәм мөһер белән расланган булырга тиешле журналда терки;

гаризаны теркәгән көннән 20 көн эчендә кертелгән документларны әлеге Тәртипнең 10 нчы пункты нигезендә карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту хакында карар кабул итә.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

документларның тулы булмаган комплектын кертү яки аларның әлеге Тәртип таләпләренә туры килмәве;

бюджет йөкләмәләре лимитыннан калган акча булмау.

Субсидия бирүдән баш тарткан очракта, Министрлык субсидия бирү турындагы гаризаны теркәгәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесенә баш тарту турында хәбәрнамә җибәрә.

12. Министрлык авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре белән Министрлык раслаган форма буенча субсидия бирү турында килешүләр төзи.

13. Министрлык бюджет акчасы белән баш эш итүче була һәм субсидияләрне Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган үз шәхси исәбеннән, Министрлык раслаган субсидия бирүгә белешмә-исәп-хисаплар нигезендә, әлеге Тәртипнең 11 нче пунктындагы өченче абзаца

күрсәтелгән вакыт чыкканнан соң биш көн эчендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең хисап исәпләренә күчерүне гамәлгә ашыра.

14. Бирелгән субсидияләр әлеге Тәртип белән билгеләнгән аларны бирү максатларын һәм шартларын бозу, субсидияләрдән максатчан файдаланмау һәм (яки) субсидияләр алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар кертү фактларын ачыклау буенча Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

15. Субсидияләр бирү турындагы килешүләр белән күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемenә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

16. Әлеге Тәртипнең 14 нче һәм 15 нче пунктларында күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемenә үз ирекләре белән кайтарудан баш тартсалар, ул законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

17. Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүләрен тикшерүне Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашыра.

18. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан Министрлыкка кертелә торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә аларның җитәкчеләренә һәм вазыйфаи затларына йөкләнә.

19. Бюджет акчасыннан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

_______________________________